| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>КУЛАНГИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.01.2025 год № 79

Колаңгы тимер юл ст. пос.

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Уставы нигезендә Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Әлеге карарны карау өчен Кайбыч муниципаль районы Советына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Башкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Советының 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар ул басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге Башлыгы — Ф.Т.Нигмәтҗанов